РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 55-0-43, факс 55-0-43

# КАРАР

**20 июль 2020 ел** **№ 1**

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Нармонка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2020 елның 4 августында 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Нармонка торак пунктында граңданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда «Нармонка авылындагы су башнясы территориясен коймау өчен» җыелган 99732 (Туксан тугыз мең җиде йөз утыз ике) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчасын «Авыл эчендәге юлларны төзү һәм ремонтлау өчен вак таш сатып алу»га тотуны хуплыйсызмы?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Т.А. Хәкимов**